Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

2018 елның 30 гыйнвары № 23/1

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карар КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2016 елның 16 июлендәге 10/3 номнрлы карары белән расланган (14.09.2016 ел.. № 11/5 карары редакциясендә), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр, авыл хуҗалыгы, җир мәсьәләләре, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков